**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423190, с. Новошешминск, ул. Советская, 80
тел.: (84348) 2-31-00, факс: (8-4348) 2-20-22

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

423190,Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80
тел.: (8-4348) 2-31-00, факс: (84348) 2-20-22

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2026 елның 12 мартыннан № 7-37

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Контроль-хисап палатасының
2025 елдагы эшчәнлеге һәм 2026 елга бурычлары турында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 56 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Контроль-хисап палатасы турындагы нигезләмәнең 19 статьясы нигезендә Контроль-хисап палатасы рәисе Р.А. Губкин Контроль-хисап палатасының 2025 елдагы эшчәнлеге һәм 2026 елга бурычлары турында хисабын тыңлаганнан һәм тикшергәннән соң, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Контроль-хисап палатасының 2025 елдагы эшчәнлеге һәм 2026 елга бурычлары турында хисабын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Контроль-хисап палатасының 2025 елдагы эшен канәгатьләнерлек дип танырга.

3. 2026 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Контроль-хисап палатасына:

3.1. Бюджетның барлык статьялары буенча бюджет ассигнованиеләрен тотуның законлылыгын һәм нәтиҗәлелеген, җирле үзидарә органнарын тотуга чыгымнарны да кертеп, тикшереп торуны гамәлгә ашырырга;

3.2. Район һәм авыл җирлекләренең муниципаль милек белән идарә итү һәм аны файдалану тәртибен үтәүне контрольдә тотарга;

3.3. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә аудит үткәрергә;

3.4. Киләсе елга һәм планлы чорга бюджет проектларына, шулай ук район һәм авыл җирлекләре бюджетларының үтәлеше турында хисапларга экспертиза үткәрергә;

3.5. Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнары хокукый актларына һәм аларның проектларына финанс-икътисадый экспертиза үткәрергә;

3.6. Вәкаләтләр чикләрендә коррупциягә каршы көрәшкә юнәлдерелгән чараларда катнашырга.

4. Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына, авыл җирлекләре Башкарма комитетларына, муниципаль бюджет учреждениеләре җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

4.1. Бюджет чараларын һәм милекне максатсыз, нәтиҗәсез куллануга юл куймаска;

4.2. Район бюджеты керемнәре һәм бюджет учреждениеләренең эшмәкәрлек эшчәнлегеннән керемнәре буенча, шул исәптән срогы чыккан дебитор бурычларны контрольдә тоту чараларын үткәрергә;

4.3. Бухгалтерлык исәбе, финанс хисаплылыгы торышына һәм финанс-бюджет дисциплинасы дәрәҗәсенә аерым игътибар бирергә, аларның дәрәҗәсен күтәрү буенча чаралар күрергә;

4.4. Муниципаль сатып алулар өлкәсендә законнар таләпләрен үтәүне, шул исәптән сатып алуларның нәтиҗәлелеген һәм нәтиҗәлелеген контрольдә тотуны гамәлгә ашырырга;

4.5. Яңа Чишмә муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә туклануны оештыруда билгеләнгән таләпләрне үтәргә;

4.6. Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль берәмлекләрендә эчке финанс контролен камилләштерү буенча эш алып барырга.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы — Е.А. Тарнавский